Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының кырык икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы
# КАРАРЫ

22 май, 2024 ел № 323

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 25 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (2019 елның 05 декабрендәге 235 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 27 номерлы, 2023елның 12 апрелендәге 224 номерлы, 2023 елның 23 декабрендәге 280 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Район Башкарма комитетының вәкаләтләре» 4 өлештә:

а) 4.3 пунктта:

- дүртенче абзацта «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыра һәм үткәрә» сүзләрен өстәргә;

- алтынчы абзацта «Район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны үстерү, тәэмин итү,» сүзләрен төшереп калдырырга.

б) 4.8 пунктының алтынчы абзацында «, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә;

в) 4.9 пунктының дүртенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- үз вәкаләтләре чикләрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;».

2. Әлеге карар, әлеге карарның 1.1 пунктындагы «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның 1.1 пунктындагы «а» пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
башлыгы урынбасары В.А. Игнатьева